ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 538-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 538-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2024 елның 29 марты
№ 2406-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Физик культура һәм спорт турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1-2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 пунктында «мәктәп спорт лигалары,» сүзләреннән соң «һәвәскәр спорт лигалары,» сүзләрен өстәргә;

2) 6 статьяның 1 өлешендәге $4^2$ пунктта «массакүләм спортны,» сүзләрен «массакүләм спортны үстерү һәм аннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү,» сүзләренә алмаштырырга;

3) 9 статьяда:

а) 2 өлештә «Физкультура-спорт оешмалары» сүзләреннән соң «спорт төрләрен үстерүдә,» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлектәге $2^1$ өлешне өстәргә:

«$2^1$. Физкультура-спорт оешмаларына федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре хисабына финанс һәм башка ярдәм күрсәтелергә мөмкин.»;

4) түбəндəге эчтəлектəге $12^2$ статьяны өстəргə:

«$12^2$ статья. **Һəвəскəр спорт өлкəсендəге эшчəнлекне җайга салу үзенчəлеклəре**

Һəвəскəр спорт өлкəсендəге эшчəнлекне җайга салу үзенчəлеклəре федераль законнарга ярашлы рəвештə башкарыла.»;

5) 14 статьяның 3 өлешен түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

«3. Спорт судьяларына квалификация категориялəре бирү, аларны раслау, алардан мəхрүм итү һəм аларны кире кайтару тəртибе һəм спорт судьяларына тиешле категориялəрне бирү өчен квалификация талəплəренең эчтəлеге, шулай ук спорт судьяларының хокуклары һəм бурычлары федераль законнар нигезендə раслана торган Спорт судьялары турындагы нигезлəмə белəн билгелəнə.»;

6) 20 статьяда:

а) түбəндəге эчтəлектəге $1^1$ өлешне өстəргə:

«$1^1$. Эш бирүчелəр эш урыннары буенча физкультура-спорт клубларын үстерүгə, шулай ук хезмəткəрлəрне физик культура һəм спорт белəн системалы шөгыльлəнүгə җəлеп итү һəм аларда сəламəт яшəү рəвеше алып бару ихтыяҗын формалаштыру максатларында аларның физкультура чараларында һəм (яки) спорт ярышларында катнашуларына ярдəм итəргə хокуклы.»;

б) 3 өлешкə «, федераль законнар нигезендə оештырылган һəм (яки) мөстəкыйль дəреслəр үткəрү һəм (яки) үткəрү өчен мөмкинлек бирү һəм (яки) физкультура чараларында һəм спорт ярышларында (шул исəптəн һəвəскəр спорт ярышларында) катнашу өчен мөмкинлек бирү юлы белəн шартлар тудыра.» сүзлəрен өстəргə.

**2 статья**

Əлеге Закон рəсми басылып чыккан көннəн үз көченə керə.

Татарстан Республикасы
Рəисе

**«Физик культура һәм спорт турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» һәм «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 1 статьясы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары» 2023 елның 25 декабрендәге 684-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнгән.

Үзгәрешләр, аерым алганда, массакүләм спорт өлкәсендә норматив-хокукый җайга салуны камилләштерүгә юнәлдерелгән. Күрсәтелгән өлештә алар физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче гражданнарның өлешен 70 процентка кадәр арттыру буенча Россия Федерациясе Президентының «2023 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен үстерүнең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечкә ирешүне тәэмин итәргә тиешләр.

Моннан тыш, Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының һәм җирле үзидарә органнарының физик культура һәм спорт өлкәсендәге вәкаләтләре аныклана, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының физик культура һәм спорт өлкәсендә массакүләм спортны үстерүдәге ролен көчәйтү өлешендә.

Закон проекты «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына аныклаучы үзгәрешләр кертүне күздә тота.

**«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Физик культура һәм спорт турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.